ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ, ХЕЗМӘТ ЭЧЕНДӘ ЙӨЗМӘККӘ!

# САБА ТАҢНАРЫ

15 март

2017 ел

№ 17 (10122)

ГАЗЕТА 1930 ЕЛНЫҢ 25 НОЯБРЕННӘН ЧЫГА saba-tannary@tatmedia.com САБИНСКИЕ ЗОРИ saby-rt.ru

**Иҗтимагый оешмаларда**

## ТОЛ ӘТИЛӘР КИҢӘШЕ

Бала тәрбияләүдә әтиләрнең җаваплылыгын күтәрү, яшүсмерләр белән эш оештыру, гаиләләрнең белем бирү йортлары белән бәйләнешләрен ныгыту максатында районыбызда бер ел элек төзелгән “Әтиләр берлеге” иҗтимагый оешмасына җитәкче итеп Саба аграр көллияте директоры Закирҗан Бикмөхәммәтов билгеләнгән иде. Төрле районнардан 370тән артык егет-кыз белем алган махсус урта уку йорты хәзер оешма үткәргән чаралар үзәгенә әйләнеп бара. Узган атнада көллият студентлары балаларын ялгыз үстерүче әтиләр белән очраштылар. Иң элек “Әтиләр берлеге” оешмасы советы әгъзалары белән киңәшмәдә Закирҗан Бикмөхәммәтов билгеләп үткәнчә, тормышта көтелмәгән хәлләр була һәм балалар үсеп килгән тигез гаиләдә әниләр генә түгел, әтиләр дә дөнья белән бергә бер кала. Шәмәрдәннән Илгиз Шәйхелисламовка да *(фотода)* язмыш шундый сынау әзерли. Бер кайгысыз яшәгәндә, 50 яшендә тол калган Илгизнең дүрт баласын үстерү аның өстенә төште. Канатың бер каерылса, парлы тормыш бик сирәкләрнең генә барып чыга. Кыскасы, Хәкимулланың күбрәк үзенә әни дә булырга туры килә. Х.Гарифуллинның ике улы да аграр көллияттә укыган. “Бередә һөнәр генә түгел, яхшы тәрбия дә алдылар, алар өчен күңелем тыныч булды. Барыгызга да уңышлар телим, әти-әниләренең кадерен исән чакта белегез”,– дип тулмаган 36 бала тәрбияләнә. Инде ул-кызлары үсеп җиткән тол әтиләр 30дан артык. Араларында төрлесе бар, билгеле. Көллияткә исә балаларына һәрчак үрнәк ата булып кала алганнарны чакырганнар иде. Әтиләр һәм совет әгъзалары бередә белем алган балалары өчен ата-аналарның күңеле һәрчак тыныч икәнлеген белеп киттеләр. “Таләпләрне йомшартсаң, урам-



**Кичә, бүген, иртәгә**

### Авыл язга әзерләнә

11 мартта “Шытсу” җәмгыяте базасында язгы кыр эшләренә әзерлек буенча семинар-киңәшмә узды. Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Гафур Хәсәншин рәислегендә узган киңәшмәдә авыл хуҗалыгы белгечләре, хуҗалык җитәкчеләре, агроном һәм инженерлар катнашты. Чыгыш ясаучылар тракторлар һәм авыл хуҗалыгы машиналары ремонтын 1 апрельгә кадәр төгәлләү, агрегатлаштыру эшенә керешү, техникаларга техник карау үткәрүгә әзерлек, чәчүлек орлыклар, минераль ашламалар барлау мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

### Рейтингыңны беләсең килсә

Саба муниципаль районы башкарма комитеты 2016 ел йомгаклары буенча районның иҗтимагый советы тарафыннан мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм мәдәният учреждениеләре күрсәткән хезмәтнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрелүе турында хәбәр итә. Бәяләү йомгаклары белән район сайтына түбәндәге сылтама аша кереп танышырга була: http://saby.tatarstan.ru/rus/reytingi-organizatsiy.htm.

### Саба “сандугачлары” – лауреатлар

Шушы көннәрдә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Венера Ганиеваның “Сандугач-Соловей” җырчы-вокалистлар конкурсы үтте. Катнашырга Россиянең төрле төбәкләреннән, хәтта Кытайдан